

Мордовия Үзәк сайлау комиссиясе мәгълvматларына караганда, респуб-ликада сайлауларда 65,13% кеше тавыш бирергә жыелган. Тавыш бирv оч кон барды. Мордовия башлыгы сайлауларында жинvне «Бердәм Россия»-«Единая Россия» партиясен гәvдәләндерvче регионыбыз Главасы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Артём Здунов яулады. Ул 78,26% тавыш жыйды. Бу хакта РФ Үзәк сайлау комиссиясе мәгълvматлары, 100% беркетмәне эшкәрткәннән сон, раслый. Икенче урында КПРФтан Дмитрий Кузякин (11,48%). Оченче урында ЛДПР вәкиле Евгений Тюрин. Анын 6,21% тавышы бар. «Россия Пенсионерлар партиясе»нән Александр Лемкин 2,64% жыйган.



«Бердәм Россия» РФ Дәvләт Думасына депутатлар сайлауда да жинv яулый. Анын очен Мордовия сайлаучыларынын 66 проценты тавыш бирде. Бу хакта РФ Үзәк сайлау комиссиясе мәгълvматлары 100% бюллетень эшкәрткәннән сон сойли. Аннан сон КПРФ - 12,99 %, ЛДПР - 7,75%, «Гадел Россия» («Справедливая Россия»)- 4,3%, «Яна кешеләр» («Новые люди»)- 2,99% һәм «Пенсионерлар партиясе»- 1, 39% тавыш жыйган.



23нче номерлы бермандатлы округ буенча Дәvләт Думасына сайлауларда 100% тавыш

эшкәрткәннән сон Юлия Оглоблина («Бердәм Россия») 57,44% тавыш белән жинде.
Анын артыннан сайлаучыларнын 13,45% тавышын жыйган Дмитрий Кузякин (КПРФ) һәм Евгений Тюрин (ЛДПР) – 8,68% тавыш жыйган. Мордовия парламентына сайлаучылар карары белән дvрт партия керәчәк. Креслоларнын кvбесен бердәмроссиялеләр биләячәк. «Бердәм Россия» МР Дәvләт Советына сайлауларда 67,21% тавыш жыя. Алар белән бергә КПРФ (14,9%), ЛДПР (9,85%), шулай ук 6,77% тавыш жыйган «Гадел Россия» партиясе эшләячәк. Мордовия халкы киләчәк очен тавыш бирде.
Тобәктәге сайлауларнын нәтижә-ләренә бердәмроссиялеләргә кvбе-сенчә РФ Президенты Владимир Путин яклавы, шулай ук  кочле кандидатлар, «Народная программа» дигән актив һәм гадел сайлау алды кампаниясе йогынты ясады.